КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 май г.Казань № 370

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче; 2016 ел, 15 февраль, 73 нче; 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче; 2019 ел, 29 июль, 629 нчы; 2020 ел, 25 август, 737 нче; 2021 ел, 19 апрель, 257 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1197 нче; 2022 ел, 8 июнь,

540 нчы; 2022 ел, 16 август, 843 нче; 2023 ел, 17 март, 261 нче; 2023 ел, 30 август, 1040 нчы, 2023 ел, 13 ноябрь, 1469 нчы, 2023 ел, 12 декабрь, 1603 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага, түбәндәге эчтәлекле 35 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «35. | «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгъ-лүмат систе-масында карау срогын 10 көн-нән артыкка бозу факты белән хәбәр-намәләр өлеше, процент | Татарстан Республикасы Дәүләт идарә-сен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br><br>монда:<br>A - хисап чорында «Эштә», «Планлаштырылган», «Хәл ителгән», «Мотив-лаштырылган кире кагу» статусына күчкән «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында бастырылган белдерүләр саны, берәмлек;<br>B - хисап чорында аннан соңгы 10 календарь көннән артык статусның берсе дә бирелмәгән «Халык контроле» Татар-стан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында 10 көннән артык эшләгән мөрәҗәгатьләр саны, берәмлек». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин